Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Пановка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге
Новоселок торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

24 ноябрь, 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең Новоселок торак пунктында 2019 елның 24 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 65 (алтмыш биш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 34 (утыз дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 34 (утыз дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «2020 елда Пановка авыл җирлегенең Новоселок торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән эшләмәүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән кала һәр балигъ булган, бер тапкыр түләүдән азат итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- җирлек территориясен төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев